ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2023 г. Казань № 419-37/кс-2023

«ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 №10-65/кс карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларны 2024 ел өчен төзәтү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга 2024 елга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 08.12.2023 № 53-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2020-2024 елларга эчә торган суга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2019 № 10-65/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 № 208-65/кс-2020, 15.11.2022 № 376-92/кс-2022 карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында

карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2019 № 10-65/кс
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2023 № 419-37/кс-2023
карары редакциясендә)

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга 2020-2024 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Чор | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Кукмара муниципаль районы | | |
| 1 | «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 30,13 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 31,31 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 31,31 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 31,90 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 31,90 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 33,31 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 34,50** |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 34,50 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 38,16 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

<**> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 № 376-92/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге